**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Урсай авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Урсай авылы № 42 “ 3 ” октябрь 2016 ел

Урсай авылы җирлеге биләмәсендә
узарасалым җыю һәм куллану
буенча, җирле референдум үткәрү
көнен билгеләү турында.

2002 елелның 12 июнендә кабул ителгән “Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу һәм сайлау хокукларының төп гарантияләре” турындагы 67 номерлы Федераль законның 15 статьясы, 2003 елның 06 октябрендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә җирле узидарәне оештыруның уртак принциплары” турындагы 113 номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, 2004 елның 24 мартында кабул ителгән “Җирле референдум” турындагы 23 номерлы Татарстан Республикасы законы, Урсай авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Урсай авылы башкарма комитетының 26 сентябрь 2016 елда чыккан 19 номерлы “Җирле референдум үткәрү” карары, Урсай авыл җирлеге Советының 26 сентябрь 2016 елда чыккан 41 номерлы “Җирле референдум үткәрү” карары нигезләрендә,

Урсай авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Урсай авыл җирлеге биләмәсендә узарасалым җыю һәм куллану буенча 20ноябрь 2016 ел көнне референдум үткәрергә.
2. Референдумда караласы мәсьәлә:

“Сез, Урсай авыл җирлеге биләмәсендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2016 елда 250 сум күләмендә узарасалым җыю белән килешәсезме. Узарасалым түләүдән көндезге якта укучы студентлар, 1 группа инвалидлар азат ителә. Узарасалымнан кергән керем түбәндәге юнәлештә тотыла:

1. Юл эшчәнлегенә карата автомобиль җирле әһәмияттәге юлларны, җирлекнең торак пунктлары чикләрендә **92 мең сум** узарасалым акчасын тоту, шуның эченнән:
   (*Гравийно юллардагы чокырларны ремонтлау эшләре Урсай авылында (Ленин, Джалил, Тукай урамнарында)- 48* мең сум, *Мөслим авылы (Такташ урамы)- 29* мең сум; *урамнарны чистарту кардан-15 мең сум ( Урсай авылы- 10 мең сум, Мөслим авылы -5* мең сум)

2.Урамнарны яктырту (плафоннар һәм лампочкалар сатып алу) **10 мең сум** күләмендә үзара салым акчасын тоту

3. Зиратларны төзекләндерү һәм тәртиптә тоту ( коймаларны тезәтү, чүп-чарны чыгару, коры агачларны кисү) -**38 мең сум** күләмендә үзара салым акчасын тоту

. (Урсай авылы -31 мең сум, Мөслим авылы - 7 мең сум)

4. янгын сүндерү гидрантларын урнаштыру һәм тезекләндерү – 15 мең сум ( Мөслим авылы Такташ урамы буенча - 10 мең сум, янгын сүндерү гидрантын тезекләндерү Урсай авылында -5 мең сум)

ӘЙЕ ЮК

3. Карар районның "Маяк" газетасында бастырыла һәм Азнакай муниципаль районының Интернет челтәрендә http://aznakyevo.tatarstan.ru веб – адресы буенча урнаштырыла.
4. Карар газетада бастырылып чыккан көненнән көченә керә.

Председатель: И.А.Абдуллин

АЗНАКАЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРСАЕВСКИЙ СОВЕТ СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1602002416
КПП 164301001